РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

БОЛЬШЕКИБЯЧИНСКИЙ
СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422065, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Большие Кибячи, ул.Ф.Энгельса, 21
тел. (84362) 42-6-24

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОЛЫ КИБӘЧЕ АВЫЛ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422065, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Олы Кибәче авылы, Ф.Энгельс урамы, 21 йорт
тел. (84362) 42-6-24

e-mail: Bkib.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР
28.01.2026 №2п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннардан файдаланган өчен түләү күләмен (наем өчен түләү) исәплəү тәртибе турында Олы Кибәче авыл башкарма комитеты тарафыннан расланган 04.06.2025 ел, №37 нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Төзелеш Министрлыгының «Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2016 елның 27 сентябрендәге №668/пр боерыгы белән расланган Социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннардан файдаланган өчен түләү күләмен билгеләүнең методик күрсәтмәләренә үзгәрешләр кертү турында" 2017 елның 19 июнендәге 892/пр номерлы боерыгы кабул ителүгә бәйле рәвештә, Россия Федерациясе Торак кодексына таянып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Олы Кибәче авыл башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Кибәче авыл җирлеге муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарны яллаучылар өчен торак урыннардан файдаланган өчен түләү күләмен (наем өчен түләү) исәплəү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1.2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Яллаучылар өчен түләүнең туры килү коэффициенты торак урыннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү) – 0,2 күләмендә билгеләнә.

Шул ук вакытта гражданнарның түбәндәге категорияләре өчен түләүләрнең туры килүенең ташламалы критерийлары билгеләнә:

-3 һәм аннан күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр өчен – 0,1;

- иминият пенсияләрен алучылар өчен («иминият пенсияләре турында» 28.12.2013 №400-ФЗ Федераль закон нигезендә) — 0,1.».

2. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә җәелдерергә.

3. Әлеге карарны " Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм җирлекнең рәсми стендларында халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Олы Кибәче авыл җирлеге башлыгы А.К.Сафин